**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 19 гыйнвар № 23

г. Казань

2016 – 2025 елларга «Фаразалана торган ихтыяҗ һәм заманча укыту шартлары нигезендә Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар булдыру» дәүләт программасын раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 ел, 23 октябрь, 2145 нче боерыгы белән расланган 2016 – 2025 елларга «Россия Федерациясе субъектларында гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар булдыруга (фаразлана торган ихтыяҗдан чыгып) булышлык күрсәтү» программасын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Министрлар КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2016 – 2025 елларга «Фаразлана торган ихтыяҗ һәм заманча укыту шартлары нигезендә Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар булдыру» дәүләт программасын (алга таба – Программа) расларга.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына Программа чараларын үтәүне тәэмин итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына шуны тәкъдим итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\23.doc

2016 – 2025 елларга «Фаразалана торган ихтыяҗ һәм заманча укыту шартлары нигезендә Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар булдыру» дәүләт программасына 1 нче кушымта

**2016 – 2025 елларга «Фаразалана торган ихтыяҗ һәм заманча укыту шартлары нигезендә Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар булдыру» дәүләт программасының максатчан күрсәткечләре (индикаторлары) (Татарстан Республикасы, муниципаль район тулаем)**

| Т/с | Күрсәткеч (индикатор) исеме | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткечнең мәгънәсе | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| 1. | **Муниципаль районда гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар саны** | берәмлек | 5584 | 6545 | 7347 | 8069 | 10810 | 2 384 | 2 324 | 2 160 | 1 390 | 1 060 |
| | шул исәптән түбәндәге юл белән булдырылган: | | | | | | | | | | | |
| 1.2. | гамәлдәге гомуми белем бирү инфраструктурасын модернизацияләү (барлыгы), | берәмлек | 5584 | 6 545 | 7 347 | 8 069 | 10 810 | 2 384 | 2324 | 2160 | 1390 | 1060 |
| | шул исәптән түбәндәге юл белән: | | | | | | | | | | | |
| 1.2.1 | мәктәп бинаалары төзү | берәмлек | 2 964 | 2 824 | 2 800 | 2 824 | 2 184 | 2 024 | 2 024 | 2160 | 1390 | 1 060 |
| 1.2.2 | мәктәп биналарына янкормалар төзү | берәмлек | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 360 | 300 | 0 | 0 | 0 |
| 1.3 | мәктәпләрнең йөкләнешен оптимальләштерү, | берәмлек | 2 620 | 3 721 | 4 547 | 5 245 | 8 626 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2. | **Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның гомуми санында бер сменада укучылар санының чагыштырма авырлыгы (барлыгы)** | процент | 92,66 | 94,00 | 96,60 | 98,50 | 98,90 | 99,00 | 99,70 | 99,80 | 100,00 | 100,00 |
| 2.1 | башлангыч гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча укучылар | процент | 89,8 | 91,70 | 94,50 | 99,50 | 100,00 | 100,00 | 100,00 | 100,00 | 100,00 | 100,00 |
| 2.2 | төп гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча укучылар | процент | 92,3 | 93,30 | 95,80 | 96,00 | 96,60 | 97,00 | 99,00 | 99,80 | 100,00 | 100,00 |
| 2.3 | урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча укучылар | процент | 95,6 | 97,00 | 99,60 | 100,00 | 100,00 | 100,00 | 100,00 | 100,00 | 100,00 | 100,00 |

2016 – 2025 елларга «Фаразалана торган ихтыяҗ һәм заманча укыту шартлары нигезендә Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларында
яңа урыннар булдыру» дәүләт программасына 2 нче кушымта
1 нче таблица

**2016 – 2025 елларга «Фаразалана торган ихтыяҗ һәм заманча укыту шартлары нигезендә Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар булдыру» дәүләт программасының гомумән алганда чаралар исемлеге**

| Т/с | Чараның исеме | Тормышка ашыру вакыты | Үтәүче | Финанслау чыганагы | Көтелә торган нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 38 яңа гомуми белем бирү объекты төзү | 2016 – 2025 еллар | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, җирле үзидарә органнары | федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты | Укучылар өчен 22254 яңа урын булдыру. Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында икенче сменаны бетерү |
| 2 | Мәктәп биналарына 2 янкорма төзү | 2016 – 2025 еллар | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, җирле үзидарә органнары | федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты | Федераль дәүләт мәгариф стандарты таләпләре нигезендә, гомуми белем бирү программаларын тормышка ашыру өчен, 660 өстәмә урын булдыру |
| 3 | Мәктәпләрнең йөкләнешен оптимальләштерү, инвесторлар җәлеп итү | 2016 – 2021 еллар | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, җирле үзидарә органнары | бюджеттан тыш чыганаклар | Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында икенче сменаны бетерү максаты белән 24759 өстәмә урын булдыру |

F:/karar/23_2.1.xls

2 нче таблица

**2016-2025 елларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре буенча кертелү еллары буенча объектларның адреслы исеме**

| Т/с | Объектның исеме | Эшләр исеме (мәктәп биналары, мәктәп биналарына янкормалар төзү, мәктәпләрне төзекләндерү, үз билгеләнешендә файдаланылмый торган биналарны гомуми белем бирү системасына кайтару, биналар һәм урыннар сатып алу, биналарны һәм урыннарны арендага алу) | Үлчәү берәмлеге (урын) | Еллар буенча күрсәткечнең мәгънәсе | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2015 | 2016 | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
| Татарстан Республикасы, барлыгы 47673 яңа урын | | | | | | | | | | | | | | |
| шул исәптән: мәктәпләр төзү – 38; мәктәпләргә янкормалар төзү – 2. | | | | | | | | | | | | | | |
| 1. | Әгерҗе районы | | | | | | | | | | | | | |
| 1.1. | ТГБМ, Күләгәш авылы | мәктәпләр төзү | 100 | | | | | | | | | | | 100 |
| 2. | Әлмәт районы | | | | | | | | | | | | | |
| 2.1 | УГБМ, Әлмәт шәһәре, «Западные Ворота» микрорайоны | мәктәпләр төзү | 800 | | | | | 800 | | | | | | |
| 3. | Арча районы | | | | | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.1. | Мәктәп, Арча шәһәре | мәктәпләр төзү | 360 | | 360 | | | | | | | | | |
| 4. | Балтач районы | | | | | | | | | | | | | |
| 4.1. | ТГБМ, Чапшар авылы | мәктәпләр төзү | 100 | | | | | | | | | | 100 | |
| 5. | Бөгелмә районы | | | | | | | | | | | | | |
| 5.1. | «4 нче УГБМ» МБГБУ | мәктәпләргә янкор-малар төзү | 300 | | | | | | | | 300 | | | |
| 5.2. | «11 нче УГБМ» МБГБУ | мәктәпләргә янкор-малар төзү | 360 | | | | | | | 360 | | | | |
| 6. | Буа районы | | | | | | | | | | | | | |
| 6.1 | УГБМ, Әлши авылы | мәктәпләр төзү | 100 | | | | | | | | | | | 100 |
| 7. | Алабуга районы | | | | | | | | | | | | | |
| 7.1 | УГБМ, 4-5 нче мик-рорайоннар, Алабуга шәһәре | мәктәпләр төзү | 800 | | | 800 | | | | | | | | |
| 8. | Зеленодольск районы | | | | | | | | | | | | | |
| 8.1 | УГБМ, Мирный микрорайоны, Зеле-нодольск шәһәре | мәктәпләр төзү | 800 | | | | | | | 800 | | | | |
| 9. | Казан шәһәре | | | | | | | | | | | | | |
| 9.1 | УГБМ, 2 нче Азино урамы | мәктәпләр төзү | 1224 | | 1224 | | | | | | | | | |
| 9.2 | УГБМ, «Салават Кү-пере» микрорайоны | мәктәпләр төзү | 1224 | | | 1224 | | | | | | | | |
| 9.3 | УГБМ, М-71 микро-районы | мәктәпләр төзү | 1500 | | | | 1500 | | | | | | | |
| 9.4 | УГБМ, «Салават Кү-пере» микрорайоны | мәктәпләр төзү | 1224 | | | | | 1224 | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 9.5 | УГБМ, «Салават Күпере» микрорайоны | мәктәпләр төзү | 1224 | | | | | | 1224 | | | | | |
| 9.6 | УГБМ, «Салават Күпере» микрорайоны | мәктәпләр төзү | 1224 | | | | | | | 1224 | | | | |
| 9.7 | УГБМ, «Мамадыш тракты» микрорайоны | мәктәпләр төзү | 1224 | | | | | | | | 1224 | | | |
| 10. | Кукмара районы | | | | | | | | | | | | | |
| 10.1 | УГБМ, Кукмара поселогы | мәктәпләр төзү | 100 | | | | | | | | | | 100 | |
| 11. | Лаеш районы | | | | | | | | | | | | | |
| 11.1 | Мәктәп, Усады авылы | мәктәп төзү | 220 | | 220 | | | | | | | | | |
| 11.2 | Мәктәп, Сокуры авылы | мәктәп төзү | 560 | | | | | | | | | 560 | | |
| 12. | Мамадыш районы | | | | | | | | | | | | | |
| 12.1 | БГБМ, Мамадыш шәһәре | мәктәп төзү | 100 | | | | | | | | | | | 100 |
| 13. | Менделеевск районы | | | | | | | | | | | | | |
| 13.1 | УГБМ, Тихоново авылы | мәктәп төзү | 100 | | | | | | | | | | | 100 |
| 14. | Минзәлә районы | | | | | | | | | | | | | |
| 14.1 | БГБМ, Элеватор поселогы | мәктәп төзү | 200 | | | | | | | | | | 200 | |
| 15. | Чаллы шәһәре | | | | | | | | | | | | | |
| 15.1 | УГБМ, «Яр буе» микрорайоны | мәктәп төзү | 800 | | 800 | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 15.2 | УГБМ, «Мәләкәс аръягы» микрорайоны | мәктәп төзү | 800 | | | | 800 | | | | | | | |
| 15.3 | УГБМ, 65 нче микрорайон | мәктәп төзү | 800 | | | | | | | | 800 | | | |
| 15.4 | УГБМ, «Мәләкәс аръягы» микрорайоны | мәктәп төзү | 800 | | | | | | | | | 800 | | |
| 16. | Түбән Кама районы | | | | | | | | | | | | | |
| 16.1 | УГБМ, 45 нче микрорайон, Түбән Кама шәһәре | мәктәп төзү | 800 | | | 800 | | | | | | | | |
| 16.2 | УГБМ, 31 нче микрорайон, Түбән Кама шәһәре | мәктәп төзү | 800 | | | | | 800 | | | | | | |
| 16.3 | УГБМ, 47 нче микрорайон, Түбән Кама шәһәре | мәктәп төзү | 800 | | | | | | | | | 800 | | |
| 17. | Яңа Чишмә районы | | | | | | | | | | | | | |
| 17.1 | УГБМ, Яңа Чишмә авылы | мәктәп төзү | 150 | | | | | | | | | | 150 | |
| 18. | Нурлат районы | | | | | | | | | | | | | |
| 18.1 | УГБМ, «Төньяк-көнчыгыш» микрорайоны, Нурлат шәһәре | мәктәп төзү | 640 | | | | | | | | | | 640 | |
| 19. | Питрәч районы | | | | | | | | | | | | | |
| 19.1 | УГБМ, Питрәч авылы, Осиновская урамы | мәктәп төзү | 260 | | | | | | | | | | | 260 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 20. | Саба районы | | | | | | | | | | | | | |
| 20.1 | УГБМ, Байлар Сабасы поселогы | мәктәп төзү | 500 | | | | 500 | | | | | | | |
| 21. | Сарман районы | | | | | | | | | | | | | |
| 21.1 | ТГБМ, Каташ-Каран авылы | мәктәп төзү | 100 | | | | | | | | | | | 100 |
| 22. | Тәтеш районы | | | | | | | | | | | | | |
| 22.1 | Генерал-майор Хапаев исемендәге Кадетлар мәктәбе, Тәтеш шәһәре | мәктәп төзү | 200 | | | | | | | | | | 200 | |
| 23. | Тукай районы | | | | | | | | | | | | | |
| 23.1 | УГБМ, Шилнәбаш авылы | мәктәп төзү | 100 | | | | | | | | | | | 100 |
| 24. | Теләче районы | | | | | | | | | | | | | |
| 24.1 | БГБМ, Караширмә авылы | | 100 | | | | | | | | | | | 100 |
| 25. | Чирмешән районы | | | | | | | | | | | | | |
| 25.1 | ТГБМ, Түбән Кәминкә поселогы | мәктәп төзү | 100 | | | | | | | | | | | 100 |
| 26. | Чистай районы | | | | | | | | | | | | | |
| 26.1 | УГБМ, «Кирпеч заводы» микрорайоны | мәктәп төзү | 360 | | 360 | | | | | | | | | |
| 26.2 | УГБМ, Полющенков урамы | мәктәп төзү | 960 | | | | | | 960 | | | | | |

**Кулланылган кыскартылмалар исемлеге:**
МАГБУ – муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесе;
МБГБУ – муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе;
УГБМ – урта гомуми белем бирү мәктәбе;
ТГБМ – төп гомуми белем бирү мәктәбе;
ДБГБУ – дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе;
БГБМ – башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе.

F:\KARAR\2016\23_2.2.doc

2016 – 2025 елларга «Фаразалана торган ихтыяҗ һәм заманча укыту шартлары нигезендә Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар булдыру» дәүләт программасына 3 нче кушымта

**2016 – 2025 елларга «Фаразалана торган ихтыяҗ һәм заманча укыту шартлары нигезендә Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар булдыру» дәүләт программасы чаралары исемлеге**

**(млн.сум)**

| Чараның исеме, финанслау чыганагы* | 2016 – 2020 елларга финанслау күләме | | | | | | Көтелә торган нәтиҗә | Программаның күрсәткечләре (индикаторлары) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2016-2020 еллар - барлыгы | шул исәптән | | | | | | |
| | | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| 1. Мәктәп биналары төзү | 10 729,33 | 2 078,59 | 2 076,27 | 2 202,53 | 2 332,31 | 2 039,64 | Программаның I этабын тормышка ашырганда, 2020 елга гомуми белем бирү оешмаларында барлык 1-4 нче һәм 10-11 (12) нче сыйныф укучылары беренче сменада укуга күчәчәк; гамәлдәге бер сменалы укыту режимы сакланып калачак. | Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар саны, шул исәптән гомуми белем бирү инфраструктурасы объектларын төзү юлы белән булдырылган урыннар саны. Гомуми белем бирү оешмаларында, шул исәптән башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча укучыларның гомуми санында бер сменада укучылар санының чагыштырма авырлыгы. |
| 2. Янкорма төзү | | | | | | | | |
| 3. Мәктәпләрнең йөкләнешен оптимальләштерү, инвесторлар җәлеп итү | | | | | | | | |
| Барлыгы | 10 729,33 | 2 078,59 | 2 076,27 | 2 202,53 | 2 332,31 | 2 039,64 | | |
| Программаның күрсәткечләре (индикаторлары) | - | 92,66 | 94,00 | 96,60 | 98,50 | 98,90 | | |

**(млн.сум)**

| **Чараның исеме, финанслау чыганагы*** | **2021 – 2025 елларга финанслау күләме** | | | | | | **Көтелә торган нәтиҗә** | **Программаның күрсәткечләре (индикаторлары)** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | **2021-2025 еллар - барлыгы** | **шул исәптән** | | | | | | |
| | | **2021 ел** | **2022 ел** | **2023 ел** | **2024 ел** | **2025 ел** | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| 1. Мәктәп биналары төзү | 9593,34 | 1778,93 | 1936,12 | 1869,66 | 1958,05 | 2050,59 | Программаның II этапбын тормышка ашырганда 2024 елга гомуми белем бирү оешмаларында барлык 5-9 нчы сыйныф укучылары беренче сменада укуга күчәчәк; гомуми белем бирү оешмаларында гамәлдәге бер сменалы укыту режимы сакланып калачак; 2025 елга барлык 1 - 11 (12) нче сыйныф укучылары 50 - 70 проценты тузган биналардан яңа мәктәп биналарына күчереләчәк | Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар саны, шул исәптән гомуми белем бирү инфраструктурасы объектларын төзү юлы белән булдырылган урыннар саны. Гомуми белем бирү оешмаларында, шул исәптән башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча укучыларның гомуми санында бер сменада укучылар санының чагыштырма авырлыгы. |
| 2. Янкормалар төзү | 494,04 | 266,04 | 228 | - | - | - | | |
| 3. Мәктәпләрнең йөкләнешен оптимальләштерү | | | | | | | | |
| Барлыгы | 10087,38 | 2044,97 | 2164,12 | 1869,66 | 1958,05 | 2050,59 | | |
| Программаның күрсәткечләре (индикаторлары) | - | 99,00 | 99,70 | 99,80 | 100,00 | 100,00 | | |

*Федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетлары мөмкинлекләрен исәпкә алып, финанслау күләмнәре фараз характерында була.

F:/karar/23_3.xls

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 19 гыйнвар, 23 нче карары белән расланды

2016 – 2025 елларга «Фаразалана торган ихтыяҗ һәм заманча укыту шартлары нигезендә Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар булдыру» дәүләт программасы

ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның максаты | Фаразалана торган ихтыяҗ һәм заманча укыту шартлары нигезендә гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар булдыру юлы белән гражданнарның һәркем файдалана алырлык башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларының дәүләт гарантияләрен тәэмин итү |
| Программаның бурычлары | Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының 1 – 11 (12) нче сыйныфларында бер сменалы укыту режимын тәэмин итү;<br>50 – 70 проценты тузган биналардан укучыларны гомуми белем бирү оешмаларының яңа биналарына күчерү |
| Программаның максатчан күрсәткечләре (индикаторлары) | Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар саны, шул исәптән гомуми белем бирү инфраструктурасы объектларын төзү юлы белән кертелгән урыннар саны;<br>Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында, шул исәптән башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча укучыларның гомуми санында бер сменада укучылар санының чагыштырма авырлыгы.<br>Соңгы нәтиҗә күрсәткечләре:<br>гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар саны – 47 673;<br>кертелгән гомуми белем бирү оешмалары объектларының гомуми саны, шул исәптән түбәндәгеләр төзелеше:<br>мәктәпләр биналары – 38;<br>мәктәпләр биналарына янкормалар – 2.<br>мәктәпләрнең йөкләнешен оптимальләштерү, инвесторлар җәлеп итү юлы белән – 24759. |
| Программаны тормышка ашыру вакытлары | I этап – 2016 – 2020 еллар;<br>II этап – 2021 – 2025 еллар |

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетлары акчасы исәбеннән Проrграмманы финанслауның гомуми күләме 2016 – 2025 елларда 20 816,71 млн.сум тәшкил итәчәк (финанслау күләмнәре, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, фараз характерында була), шул исәптән:<br>2016 елда – 2078,59 млн.сум;<br>2017 елда – 2076,27 млн.сум;<br>2018 елда – 2202,53 млн.сум;<br>2019 елда – 2332,31 млн.сум;<br>2020 елда – 2039,64 млн.сум;<br>2021 елда – 2044,97 млн.сум;<br>2022 елда – 2164,12 млн.сум;<br>2023 елда – 1869,66 млн сум;<br>2024 елда – 1958,05 млн.сум;<br>2025 елда – 2050,59 млн.сум |
| Программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр һәм аның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Программаның 1 нче этабын (2016 – 2020 еллар) тормышка ашырганда:<br>2020 елга гомуми белем бирү оешмаларында барлык 1 – 4 нче һәм 10 – 11 (12) нче сыйныф укучылары беренче сменада укуга күчәчәкләр;<br>гамәлдәге бер сменалы укыту режимы сакланып калачак.<br>Программаның икенче этабын (2021 – 2025 еллар) тормышка ашырганда:<br>2024 елда гомуми белем бирү оешмаларында барлык 5 – 9 нчы сыйныф укучылары беренче сменада укуга күчәчәкләр;<br>гомуми белем бирү оешмаларында бер сменалы укыту режимы сакланып калачак;<br>2025 елга барлык 1 – 11 (12) нче сыйныф укучылары 50 – 70 проценты тузган биналардан мәктәпләрнең яңа биналарына күчереләчәкләр |
| Программаны җаваплы үтәүче һәм бергә үтәүчеләр | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |

## I. Программаның структурасы

Программа аны хәл итүгә юнәлдерелгән мәсьәлә тасвирламасы

Әлеге Программаны тормышка ашыру зарурлыгы сыйфатлы белем алу өчен шартлар тудыру буенча хәл ителә торган бурычларның югары социаль әһәмияткә ия булуына бәйле. Моның өчен уку-укыту эшчәнлегенең барлык төрләрен бер укыту сменасында оештыру, аларны гамәлгә ашыру шартларының куркынычсызлыгы һәм уңайлыгы тәэмин ителергә тиеш.

Ике сменада уку, сыйфатлы белем бирүдән файдалана алуны, укучыларның дәрестән тыш эшчәнлек төрләрен оештыру мөмкинлеген, балаларга өстәмә белем бирү хезмәтләре күрсәтү сыйфатын киметеп, гомуми белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф стандартларын сыйфатлы рәвештә тормышка ашырырга мөмкинлек бирми. Шунысы мөһим, Татарстан Республикасында дәресләрне өч сменада алып баручы мәктәпләр юк.

Программа Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 ел, 23 октябрь, 2145 нче боерыгы белән расланган 2016 – 2025 елларга «Россия Федерациясе субъектларында гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар булдыруга (фаразлана торган ихтыяҗдан чыгып) булышлык күрсәтү» программасын үтәү йөзеннән эшләнде.

Укучыларның физик, психологик һәм социаль сәламәтлеген саклау һәм ныгытуны гарантияләүче, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү максатларына ирешүне, аның югары сыйфатын тәэмин итүче белем бирү мохитен булдыру Программаны тормышка ашыру нәтиҗәсе булып тора.

Алда санап үтелгән һәр гомуми белем бирү баскычы буенча төп белем бирү программасы дәрес һәм дәрестән тыш эшчәнлек аша белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма тарафыннан тормышка ашырыла.

Гомуми белем бирү оешмасының дәрестән тыш эшчәнлеге 11 ел укытуга якынча 3800 сәгать тәшкил итә.

Шулай ук гомуми белем бирү оешмасында белем бирү һәм административ-хуҗалык эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле булган барлык төр уңайлыклар булырга тиеш: уку-укыту бүлмәләре (шул исәптән заманча предметлар кабинетлары, лабораторияләр, уку-укыту остаханәләре), мәгълүмат-китапханә, спорт бүлмәләре, дәрестән тыш эшчәнлек, түгәрәкләр һәм секцияләр өчен бүлмәләр, шулай ук туклануны оештыру өчен, медицина билгеләнешендәге бүлмәләр, административ һәм кирәкле җиһазлар белән тәэмин ителгән башка бүлмәләр, шул исәптән сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балаларга белем бирү эшчәнлеген оештыру өчен.

Татарстан Республикасында 2015/2016 уку елында 1417 мәктәп эшли, һәм аларда 377 254 укучы белем ала. Шул ук вакытта 135 мәктәптә дәресләр ике сменада оештырыла (узган елда – республиканың 140 мәктәбендә).

Укыту ике сменада оештырыла торган мәктәпләр күбесенчә шәһәрләрдә урнашкан, шул исәптән:

60 мәктәп – Казан шәһәрендә;

16 мәктәп – Чаллы шәһәрендә;

8 мәктәп – Түбән Кама муниципаль районында,

7 мәктәп – Зеленодольск муниципаль районында,

10 мәктәп – Чистай муниципаль районында.

Ел саен мондый төр мәктәпләр саны кими (2010 елдан – 174 тән 135 кә).

Республикада 28 муниципаль районда укыту бер сменада гына оештырылган; 17 (2014 елда – 19, 2013 елда – 24) муниципаль берәмлектә укучылар ике сменада укый. 2014/2015 уку елында икенче сменада – 31 039 мәктәп укучысы (8,4 %), 2015/2016 уку елында 30 852 укучы (8,23 %) шөгыльләнде.

Әлеге балаларның иң күп өлеше түбәндәге муниципаль берәмлекләрдә: Чистай (32,9 %), Арча (17,6 %), Алабуга (14,5 %), Нурлат (13,0 %), Зеленодольск (12,3 %) муниципаль районнарында, Казан (13,6 %) һәм Чаллы (6,5 %) шәһәрләрендә.

Бу елда әлеге күрсәткеч Арча, Биектау, Лениногорск, Түбән Кама, Балык Бистәсе районнарында, шулай ук Чаллы һәм Казан шәһәрләрендә яхшырды.

Буа, Чүпрәле, Сарман муниципаль районнарында бу уку елыннан ике сменалы укытуны бетерделәр.

Әлеге күрсәткеч буенча нәтиҗәләр Бөгелмә, Зеленодольск, Алабуга, Лаеш һәм Чистай районнарында начарайды.

Кукмара муниципаль районында узган елда ике сменалы укыту булмаса, быел барлыкка килде.

Шунысын да исәпкә алырга кирәк, 2020 елга кадәр гомуми белем бирү оешмаларында укучылар саны 70,6 мең кешегә кадәр үсәчәк. Демографик фаразны исәпкә алганда республиканың гомуми белем бирү оешмаларында икенче сменада укучылар өлеше 11,6 %ка кадәр артачак (21 176 кеше).

Яңа урыннар булдыру буенча 2016 – 2020 елларга гомуми фараз ихтыяҗы – 38355 урын, 2021 – 2025 елларда 9318 урын тәшкил итә.

Гомуми белем бирү сыйфатыннан һәркем файдалана алуны арттырыр өчен, гомуми белем бирү оешмаларының 1 – 11 (12) нче сыйныфларында бер сменалы укыту режимын, шулай ук укучыларны 50 – 70 проценты тузган биналардан гомуми белем бирү оешмаларының яңа биналарына күчерүне тәэмин итәргә кирәк.

Ике сменалы укытуны бетерү һәм бер сменалы укытуны тәэмин итү максатында, 2020 елга кадәр түбәндәге төп чараларны үткәрергә кирәк:

яңа мәктәпләр төзү – 16 оешма;

мәктәпләрнең йөкләнешен оптимальләштерү, инвесторларны җәлеп итү – 24759.

Татарстан Республикасында 50 – 70 проценты тузган иске мәктәпләр саны – 12.

Барлык 1 – 11 (12) нче сыйныф укучыларын 50 – 70 проценты тузган биналардан яңа биналарга күчерү өчен, 2021 елдан 2025 елга кадәр 12 гомуми белем бирү оешмасының яңа биналарын төзергә кирәк.

Программа ике этапта тормышка ашырылачак: I этап – 2016 – 2020 еллар; II этап – 2021 – 2025 еллар.

Программаның максатчан күрсәткечләре түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар саны – барлыгы (берәмлек), шул исәптән түбәндәге юл белән булдырылган:

капиталь ремонт үткәрү (яңа урыннар булдыру максаты белән);

федераль бюджет акчасы исәбеннән финанслашу кысаларында мәктәп бинаалары төзү;

мәктәпләр биналарына янкормалар төзү;

мәктәпләрнең йөкләнешен оптимальләштерү;

гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның гомуми санында бер сменада укучылар санының чагыштырма авырлыгы – барлыгы (%).

Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның гомуми саны 479 382 кеше күләмендә булганда икенче сменаны тулысынча бетерү 2023 елга тормышка ашырылачак.

50 – 70 проценты тузган мәктәпләр биналарыннан тулысынча күчерү 2025 елга гамәлгә ашырылачак.

## II. Программаның максаты һәм бурычлары, аны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары, шулай ук Программаны тормышка ашыруның максатчан күрсәткечләре (индикаторлары)

**Программаның максаты** – фаразалана торган ихтыяҗ һәм заманча укыту шартлары нигезендә гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар булдыру юлы белән гражданнарның һәркем файдалана алырлык башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларының дәүләт гарантияләрен тәэмин итү.

**Программаның бурычлары:**

Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының 1 – 11 (12) нче сыйныфларында бер сменалы укыту режимын тәэмин итү.

50 – 70 проценты тузган биналардан укучыларны гомуми белем бирү оешмаларының яңа биналарына күчерү.

Программаның максатчан күрсәткечләре (индикаторлары) әлеге Программага теркәлгән 1 нче кушымтада китерелә.

Программа 2 этапта тормышка ашырыла:

I этап – 2016 – 2020 еллар;

II этап – 2021 – 2025 еллар.

**I этапта** 2020 елга 1 – 4 нче һәм 10 – 11 (12) нче сыйныф укучыларын бер сменалы укуга күчерү һәм гамәлдәге бер сменалы укыту режимын саклап калу **күздә тотыла**.

**II этапта** 2024 елга 5 – 9 нчы сыйныф укучыларын бер сменалы укуга күчерү һәм бер сменалы укыту режимын саклап калу **планлаштырыла**.

2025 елга барлык 1 – 11 (12) нче сыйныф укучылары 50 – 70 проценты тузган биналардан мәктәпләрнең яңа биналарына күчереләчәк.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы:

Программа чараларын тормышка ашыруга бүленеп бирелә торган финанс чарасыннан нәтиҗәле файдалануны тәэмин итә;

Программаны тормышка ашыру буенча квартал саен хисаплылык алып баруны, шулай ук Программа чараларын тормышка ашыруны мониторинглауны оештыра;

Программа чараларын үтәү кысаларында Программаны үтәүчеләр эшчәнлеге белән идарә итүне гамәлгә ашыра;

кирәк булган очракта Программа чараларын тормышка ашыру барышына эксперт тикшерүләре оештыра;

Программа чараларын тормышка ашыруга бүленеп бирелә торган акчадан максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тота.

Программаның максатына ирешү һәм бурычларын үтәү вакытлар, ресурслар, үтәүчеләр һәм нәтиҗәләр буенча яраштырылган чаралар комплексын үтәү юлы белән гамәлгә ашырыла.

## III. Программа чаралары

Программаның төп бурычларын тормышка ашыру максатларында, 2016 – 2025 елларда түбәндәге чаралар күздә тотыла:

1. Белем бирү процессын оештыруның заманча таләпләренә туры килүче бертип проектлар кулланып, мәктәпләр төзү, бер сменада укытуны оештыру максаты белән төрле эшчәнлек төрләре өчен файдаланырга мөмкинлек бирә торган бүлмәләрне үзгәртү мөмкинлеге – 38 гомуми белем бирү оешмасы.

2. Гамәлдә булган гомуми белем бирү инфраструктурасын модернизацияләү, шул исәптән бер сменада укытуны оештыру максаты белән мәктәп биналарына янкормалар төзү – 2 гомуми белем бирү оешмасы.

3. 50 – 70 проценты тузган биналарда укучыларны яңа мәктәп биналарына күчерү өчен гомуми белем бирү оешмалары төзү – 12 гомуми белем бирү оешмасы.

4. Мәктәпләрнең йөкләнешен оптимальләштерү (гамәлдәге урыннардан нәтиҗәле файдалану; гомуми белем бирү оешмаларының төрле типтагы бүлмәләреннән нәтиҗәле файдалануны күтәрү, оештыру кадрлар карарлары кабул итү), инвесторларны җәлеп итү. 2021 елга кадәр (2021 елны да кертеп) гамәлдәге мәктәп мәйданнарыннан нәтиҗәле файдалануга юнәлдерелгән оптимальләштерү чаралары үткәрү, инвесторларны җәлеп итү юлы белән 24759 укучылар урыны тәэмин итү планлаштырыла.

Татарстан Республикасы буенча тулаем һәм муниципаль берәмлекләр яктылыгында адреслы тиешле чаралар исемлеге әлеге Программага теркәлгән 2 нче кушымтада китерелә.

## IV. Программаны финанслар белән тәэмин итү

Программа чараларын финанслау федераль, республика һәм җирле бюджетлар акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Әлеге Программага теркәлгән 3 нче кушымта нигезендә, федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетлары акчасы исәбеннән Программаны финанслауның гомуми күләме 2016 – 2025 елларга 20816,71 млн.сум тәшкил итәчәк (финанслау күләмнәре, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, фараз характерында була), шул исәптән:

2016 елда – 2078,59 млн.сум;
2017 елда – 2076,27 млн.сум;
2018 елда – 2202,53 млн.сум;
2019 елда – 2332,31 млн.сум;
2020 елда – 2039,64 млн.сум;
2021 елда – 2044,97 млн.сум;
2022 елда – 2164,12 млн.сум;
2023 елда – 1869,66 млн сум;
2024 елда – 1958,05 млн.сум;
2025 елда – 2050,59 млн.сум

## V. Программаны тормышка ашыру механизмы

Программаның җаваплы үтәүчесе-яраштыручысы – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы.

Программаны бергә үтәүчеләр түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы;

Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы:

1) Программаны тормышка ашыруны планлаштыруны, оештыруны һәм тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра;

2) үз компетенциясе чикләрендә Программаны үтәү өчен кирәкле хокукый актлар эшли;

3) Программаны тормышка ашыру барышына эксперт тикшерүләре оештыра;

4) Программаны тормышка ашыруны мониторинглау өчен максатчан күрсәткечләр (индикаторлар) исемлеген эшли;

5) Программа чараларын тормышка ашыруга бүленеп бирелә торган финанс чарасыннан нәтиҗәле файдалануны тәэмин итә;

6) Программаны тормышка ашыру буенча квартал саен хисаплылык алып баруны, шулай ук Программа чараларын тормышка ашыруны мониторинглауны оештыра;

7) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә Программа чаралары турында хәбәр итә;

8) Программага, шул исәптән федераль, республика яки җирле бюджетлар акчасы исәбеннән объектларны финанслауның кимүен яки артуын, конкурс процедуралары йомгаклары буенча акчаны экономияләүне, Программа буенча бүленеп бирелгән акча чикләрендә башкарылган эшләрне исәпкә алып, финанслау күләмнәренә үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр әзерли. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Программага үзгәрешләр кертү турында норматив хокук актын кабул иткәннән соң, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары белән, Программага кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, өстәмә килешүләр төзи;

9) Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары белән Программада билгеләнгән субсидияләр исәп-хисабы нигезендә, Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең норматив хокук актлары белән расланган форма буенча тиешле финанс елына килешүләр төзи.

## VI. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаның нәтиҗәлелеге (Э) ел саен гамәлдәге ирешелгән максатчан күрсәткечләр (индикаторлар) мәгънәләрен аларның планлаштырыла торган (әлеге Программага теркәлгән 1 нче кушымтада китерелгән) мәгънәләре белән чагыштыру юлы белән бәяләнә һәм түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Э = \left[1 - \frac{1}{n} \times \sum_{i-1}^{n} \frac{\left|x_i - x_{факт,i}\right|}{x_i}\right] \times 100\% \ ,$$

монда:

n – максатчан индикаторлар саны;

xi – әлеге Программага теркәлгән 1 нче кушымтада китерелгән i-нче максатчан күрсәткечнең (индикаторның) планлаштырыла торган мәгънәсе;

xфакт,i – i-нче максатчан күрсәткечнең (индикаторның) гамәлдәге ирешелгән мәгънәсе.

Әгәр максатчан күрсәткечнең (индикаторның) гамәлдәге ирешелгән мәгънәсе әлеге Программага теркәлгән 1 нче кушымтада күздә тотылган бу күрсәткечнең (индикаторның) тиешле планлаштырыла торган мәгънәсеннән күбрәк булса, i-нче максатчан күрсәткечнең (индикаторның) планлаштырыла торган мәгънәсе һәм i-нче максатчан күрсәткечнең (индикаторның) гамәлдәге ирешелгән мәгънәсе аермасының мәгънәсе нульга тигез санала.

Программаны тормышка ашыру нәтиҗәлелеге турында йомгак нәтиҗәлелелекнең сан ягыннан мәгънәсенә бәйле рәвештә ясала. Әгәр нәтиҗәлелекнең сан ягыннан мәгънәсе 80% ка тигез яки аннан күбрәк булса, Программаны тормышка ашыру нәтиҗәле санала.

**Программаның 1 нче этабын (2016 – 2020 еллар) тормышка ашырганда:**

2020 елга гомуми белем бирү оешмаларында барлык 1 – 4 нче һәм 10 – 11 (12) сыйныф укучылары беренче сменада укуга күчәчәк, гамәлдәге бер сменалы укыту режимы сакланып калачак.

**Программаның 2 нче этабын (2021 – 2025 еллар) тормышка ашырганда:**

2024 елга гомуми белем бирү оешмаларында барлык 5 – 9 нчы сыйныф укучылары беренче сменада укуга күчәчәк, гомуми белем бирү оешмаларында гамәлдәге бер сменалы укыту режимы сакланып калачак;

2025 елга барлык 1 – 11 (12) нче сыйныф укучылары 50 – 70 проценты тузган биналардан яңа мәктәп биналарына күчереләчәк.

Программаны тормышка ашыру йомгаклары буенча барлык мәктәп укучылары бер сменада укыячак, укучыларның 100 проценты югары тузу дәрәҗәсе булган мәктәп биналарыннан яңа мәктәпләргә күчәчәк.

## VII. Программаны тормышка ашыру куркынычлары анализы

Программаны федераль, республика һәм җирле бюджетлар акчасы исәбеннән җитәрлек күләмдә финанслямау Программаны тормышка ашыруга тискәре йогынты ясарга мөмкин.

Әлеге факторның тискәре йогынтысын минимальләштерү максатында, бюджеттан тыш финанслау чыганакларын, федераль бюджет акчасын җәлеп итү мөмкинлеге, шулай ук Татарстан Республикасында бер сменалы укыту режимын тәэмин итүгә, 50 – 70 проценты тузган биналарда укучыларны яңа мәктәп биналарына күчерүгә юнәлдерелгән башка программа механизмнарын эшләү планлаштырыла.

---